| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО - КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

№ 1827/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«18» 12 2025

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 31.03.2014 ел, № 191 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Рәсәй Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 19-21 статьялары, “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм “Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының” Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында” 24.09.2025 ел, № 1396/о боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.12.2025 ел, № 10-53/15428 бәяләмәсен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 31.03.2014 № 191 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына (Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы 13.11.2020 № 17, 06.10.2022 № 122, 30.08.2023 № 161, 14.12.2023 № 177 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 өлештә "Территориаль планлаштыру турында Нигезләмә”:

“Мөслим муниципаль районын территориаль планлаштыру буенча җирле (район) әһәмияттәге чаралар исемлеге” 1 бүлегенә әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә “Су белән тәэмин итү челтәрләрен үстерү чаралары” 1.6

пункты өстәргә;

"Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы картасы белән тулыландырырга. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә 1.6.1 таблицада күрсәтелгән җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы".

2. Территорияләрне үстерү департаменты агломерацияләрне үстерү идарәсенең төньяк-көнчыгыш районнарны үстерү бүлегенә (Н.Г.Елагинага) тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыруны;

әлеге боерыкны "Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

әлеге боерыкны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А. Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н. Кудряшев

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 18.12.2025 № 1827/о боерыгына 1 нче
кушымта

## 1.6. Су белән тәэмин итү челтәрләрен үстерү гамәлләре

1.6.1 нче таблица

Муниципаль районның урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге су белән тәэмин итү объектларының төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары, урнашу урыны, шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә

| № | Урнашу урыны | Объект исеме | Объектның билгеләнеше | Объектның статусы | Объектка характеристика | Гамәлгә ашыру срогы | Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Михайловское авылы 16:29:160401:571 җир кишәрлекләре | Су күтәрү манарасы | Куллланучыларны су белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру | Реконструкция ләүгә планлаштырыла торган | 40:м3 | 2035 | Санитар саклау зонасының беренче поясы 10 м (2.4.2 пункты СанПиН 2.1.4.1110-02 “Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы сууткәргечләрне санитар саклау зоналары”) |

Искәрмәләр:

- объектның характеристика якынча һәм проектлауның алдагы стадияләрендә үзгәрергә мөмкин;

– – су белән тәэмин итү корылмаларын реконструкциягә чараларын гамәлгә ашыру, шул исәптән СанПиН 2.1.4.1110-02 “Су белән тәэмин итү чыганакларын санитария саклау зонасы һәм эчәргә яраклы суүткәргечләр” таләпләренә туры китереп, өч полосадан торган су белән тәэмин итү чыганаклары өчен санитария-саклау зонасын оештыру, әйләнә-тирә мохит һәм санитар-эпидемиологик законнар нормаларын һәм таләпләрен үтәгән очракта гына мөмкин;

– торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан һәм файдалы казылмалар яткан мәйданнарда урнашкан җир кишәрлекләрен төзү бары тик җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы рөхсәтен алганнан соң гына рөхсәт ителә ("Җир асты байлыклары турында" 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Рәсәй Федерациясе Законының 25 статьясы).

Приложение № 2
к приказу Министерства
строительства, архитектуры
и жилищно-коммунального
хозяйства
Республики Татарстан
от 18.12.2025 № 1827/о

